Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы

# КАРАР

27 март, 2024 ел № 11

Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Адай авылы торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Адай авылы торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы Адай авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Зур Сәрдек авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елның 7 апреленә 13 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Адай авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы Адай авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын һәм 2024 елның 7 апреленә 20 сәгать 00 минутка икенче этабын үткәрүне билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Адай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы карарына түбәндәге мәсьәлә буенча үзгәрешләр кертүгә ризамы: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, гомуми белем бирү мәктәпләре укучыларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм инвалидлардан, I төркем инвалидларыннан, 18 яшькә кадәр 5 һәм аннан да күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләрдән, 75 яшьтән өлкәнрәк ялгыз пенсионерлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 800 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Адай авылы урамнары юлларын вак таш салып ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Адай авылында урам-юл челтәрен карап тоту (шартнамә буенча түләү);
- Адай авылы артезиан скважиналары өчен тирәннщн суырту насосы сатып алу;
- Адай авылында янгын гидрантлары урнаштыру, янгынга каршы комплектлау материаллары сатып алу, янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен махсус машинаны тоту (ягулык-майлау материалларына чыгымнар, транспорт йөртүчене тоту);
- Адай авылында урам яктыртуны көйләү өчен урам яктырткычлары һәм махсус җиһазлар сатып алу;

(Адай авылында яссы спорт корылмаларын төзү һәм булганнарын ремонтлау; хоккей мәйданчыгына суүткәргеч челтәрләре сузу

2023 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы карарында күрсәтелгән эш төрләрен үзгәртү өлешендә түбәндәге эшләр белән:

урам яктыртуны ясау (Адай авылында урам яктыртуны көйләү өчен урам яктырткычлары һәм махсус җиһазлар сатып алу);

су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (Адай авылы артезиан скважиналары өчен тирәннщн суырту насосы сатып алу);

янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Адай авылында янгын гидрантлары урнаштыру, янгынга каршы комплектлау материаллары сатып алу, янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен махсус машинаны тоту (ягулык-майлау материалларына чыгымнар, транспорт йөртүчене тоту);

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Адай авылы урамнары юлларын вак таш салып ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

торак пункт территориясен төзекләндерү (Адай авылында яссы спорт корылмаларын төзү һәм булганнарын ремонтлау; хоккей мәйданчыгына суүткәргеч челтәрләре сузу; балалар уен мәйданчыгын карап тоту һәм ремонтлау; Адай авылы территориясендә үләнне чабу);

каты көнкүреш калдыкларын туплау мәйданчыкларын төзү, каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Зур Сәрдек авыл җирлеге башлыгы Ф.М. Фәттахов